ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.05.2020 ел Баулы шәһәре №107

Баулы муниципаль районында
аренда түләүләрен түләүдән
азат итеп кече һәм урта эшмәкәрлек
субъектларына ярдәм итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында»гы 2020 елның 3 апрельендәге 434 нче карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге «2020 елның апрель-июнь айлары өчен Татарстан Республикасы дәүләт казнасын тәшкил иткән дәүләт мөлкәтен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү турында»гы 821 - р номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУга Баулы муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итә торган муниципаль милекне (шул исәптән җир кишәрлекләре), һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба - муниципаль милек) арендага бирү шартнамәләре буенча тәэмин итәргә:

а) арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында аеруча зыян күргән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары исемлегенә кертелгән (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген

раслау турында”гы 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән 7 эш көне дәвамында 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү.

Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү шарты: аренда килешүендә, күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен, аннан файдалану максатларында, муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булу һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булу;

б) Баулы муниципаль районы сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен әлеге карарның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә, аренда түләүләрен түләүдән азат итү мөмкинлеге Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр режимы кертелгән көнгә кадәр яисә гадәттән тыш хәлләр режимы кертелгәнчегә кадәр муниципаль мөлкәтне (әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланылган) арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында, 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адрес буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров